СОВЕТ
МАСАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423753, д. Масады,
ул.Нефтяников, д.18
Тел. 3-44-49

АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЭСЭДЕ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423753, Мэсэде авылы,
Нефтяниклар ур.,18нче йорт.
Тел. 3-44-49

РЕШЕНИЕ КАРАР

«2» март 2021 ел №3

**Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Советының 17.03.2016 ел, №4 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Мәсәде авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы , «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Мәсәде авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Мәсәде авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында, Мәсәде авыл җирлегенең 17.03.2016 ел №4 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 пунктның «в» пунктчасында «оешмалар» сүзләреннән соң, «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә»;

1.2. 13 пунктта «оешмалар» сүзләреннән соң, «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Мәсәде авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Мәсәде авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.Р.Мингазетдинова